БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ • ДЕТСКИЙ ЖУРНАЛ • CHILDREN'S MAGAZINE

№10.2016

Салават күпере

0+



ISSN 0868-4545

«SK» КАЛЕНДАРЬ

ОКТЯБРЬ

ДҮШӘМБЕ	СИШӘМБЕ	ЧӘРШӘМБЕ	ПӘНҖЕШӘМБЕ	ҖОМГА	ШИМБӘ	ЯКШӘМБЕ
					1 Өлкәннәр көне	2 Кулчатыр белән йөрү көне
3 Бөтендөнья архитектура көне	4 Хайваннарны саклау көне	5 Укытучылар көне	6 Туганнар һәм якыннар көне	7 Бөтендөнья елмаю көне	8 Микродулкынлы мич туган көн	9 Бөтендөнья почта көне
10 Яраткан китап көне	11 Өйдә ял итү көне	12 Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре көне	13 Резин итекләр көне	14 Фото пленкасы көне	15 Бөтендөнья кул юу көне	16 Бөтендөнья азык-төлек көне
17 Диванда яту көне	18 Тәм-томнар көне	19 Бөтенроссия лицейчылар көне	20 Халыкара пешекчеләр көне	21 Алма көне	22 Ксерокс күчермәсе туган көн	23 Реклама хезмәткәрләре көне
24 Спецназ көне	25 РФ таможнячысы көне	26 Автомобиль йөртүчеләр көне	27 Кара чәчле кызлар көне	28 Халыкара анимация көне	29 Гербарий ясау көне	30 Көзге табигатьтә ял итү көне

ДҮШӘМБЕ: 31 Хэллоуин

© «Салават күпере», 2016 ел.

Республика балалар клиник хастаханәсендә дәваланучы нәниләр.

МИН «САЛАВАТ КҮПЕРЕ»Н УКЫЙМ!



Даниель, 5 яшь, Әмир, 6 яшь, Зәринә, 5 яшь, Роман, 6 яшь, Яр Чаллы.



Азамат, 2 яшь, Казан.



Эмилия, 5 яшь, Яшел Үзән, Эмилия, 3 яшь, Шәмәрдән.



Рамил, 4 яшь.



Мәлик, 8 яшь, Казан.



Николай, 8 яшь, Казан.

Сәламәтлек – зур байлык



Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры Адель Юныс улы ВАФИН

Кадерле балалар!

Саулык, сәламәтлек дигән сүзләр сезгә яхшы таныш. Сәламәтлек бала чактагы хәрәкәтле уеннардан, суда йөзүдән, велосипедта, чаңгыда йөрүдән, чана шуудан башлана.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәр кешенең саулыгын кайгыртып тора. Моның өчен республикада күп төрле эшләр башкарыла. Авырган очракта кешеләр табиблар янына бара. Алар исә халыкка тиешле ярдәм күрсәтә, дәвалыйлар. Безнең министрлыкны «табиблар министрлыгы» дип атарга да мөмкин.

Республикабызда олылар өчен шәһәр, район хастаханәләре эшләсә, Казанда урнашкан Республика балалар клиник хастаханәсе сабыйларны дәвалау белән генә шөгыльләнә.

Татарстанда яшәүчеләрнең сәламәтлеген кайгырту – безнең төп бурычыбыз. Мин барчагызга да сәламәтлек телим!



Республика балалар клиник хастаханәсенең баш табибы Рафаэль Фирнаял улы ШӘВӘЛИЕВ

Хөрмәтле әти-әниләр!

Сәламәтлек – ул һәр кешенең зур байлыгы, тормышның төп нигезе. Медицина ничек кенә алга китмәсен, ул кешене барлык авырулардан да арындыра алмый. Баланың сәламәтлеген ныгыту – ул вакытлы чара түгел, ә кешене туганнан алып соңгы көненә кадәр тәрбияләү идеялогиясе. Кечкенәдән балагызны уен аша сәламәт яшәү рәвеше алып барырга, файдалы гадәтләргә өйрәтәсез икән – үзегезгә өстәмә балл язгыз, ә ул балл һәрхәлдә, тормышның теләсә кайсы өлкәсендә уңышларга ирешергә ярдәм итәчәк.



Ата-ананың иң зур бәхете – баласын сәламәт, акыллы һәм игелекле итеп үстерү. Димәк, без бер-беребезгә бәхетле булырга ярдәм итә алабыз.



Шәүкәт Галиев (Шәүкәт Галиулла улы Һидиятуллин) 1928 елның 20 ноябрендә Апас районы Олы Бакырчы авылында крестьян гаиләсендә туа. 1943 елда җидееллык мәктәпне тәмамлый һәм туган колхозында хезмәт куя.

1953 елдан алып ул «Чаян» журналы редакциясендә эшли. 1959-1961 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда укый. 1961-1971 елларда ул – профессиональ язучы, ә 1984 елга кадәр Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият редакциясе мөдире була.

Ш.Галиевның беренче шигырьләре 1948 елда басылып чыга. Шуннан соң шагыйрь үзенең әдәби иҗат эшен киң җәелдереп җибәрә.

Ш.Галиев – танылган балалар шагыйре. 1972 елда бу өлкәдәге әсәрләре өчен ул Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. 1980 елда аның балалар өчен язылган шигырьләре «Заяц на зарядке» исеме астында рус теленә тәрҗемә итеп басыла. 1982 елда шагыйрь бу китабы өчен Халыкара бүләккә – Г.Х.Андерсен исемендәге Мактаулы Дипломга лаек була.

2011 елда Шәүкәт Галиев арабыздан китте.

ИҢ БАЙ КЕШЕ



«Иң бай кеше кем?» – дисезме,
Ул кеше – мин, белегез.
Мактана дип уйласагыз –
Килегез дә күрегез.
Йортыбыз бар. Әти аны
Салды үз кулы белән.
Өйрәтте ул, мин дә хәзер
Балта тотарга беләм.
Әти кебек, әнием дә
Байлыгы безнең өйнең.
Нинди генә хәлләрдә дә
Ул таба безнең көйне.
Әбием дә, бабаем да–
Икесе дә исәннәр.
Алар белән яшәү рәхәт –
Ниләр генә дисәң дә.
Сеңлем дә бар, энем дә бар –
Алар да безнең байлык.
Ходай биргән тагын безгә
Иң зур байлык – ул саулык.

Шаукат Галиев

КТО САМЫЙ БОГАТЫЙ?

Однажды меня спросили ребята:
– Скажи, кто на свете
самый богатый?
Я честно ответил на это: «Друзья,
Самый богатый на свете – я!»
У нас есть дом – посмотрите сами –
Отец его строил своими руками.
Он и меня научил. С тех пор
Ловко держу я в руках топор.
И мама наша – богатство большое:
В руках ее спорится дело любое.
Мама всегда нам помочь готова,
Каждому скажет доброе слово.
У нас и бабушка есть, и дед.
Бодры! Пусть даже им много лет
Трудно порою за ними угнаться.
Жить с ними рядом
большое богатство.
Сестричка есть у меня и брат –
Богатству такому я очень рад!
И все мы здоровы! –
А это, братцы,
Самое главное наше богатство!

Перевод Талии ШАРАФИЕВОЙ





Shawket Galiyev

THE RICHEST PERSON

If you wonder who's the richest,
I know for sure it's myself.
Please don't think I'm a bragger,
Come and see for yourself.
We have a house built by my dad.
He constructed it from scratch.
My dad taught me the craft of axe,
I know what and how to attach.
Like my father, my dear mom
Is the treasure of the house.
No matter what might happen,
She'll find a way to our hearts.
Both my grandmother and grandfather
Are as sound as the bell.
Seeing them often is a pleasure
And a real joy by any measure.
I have a sister and a brother –
We consider them our wealth.
There's another precious treasure
Given in life – it's our health.

Translation Dilyara Sharifullina

КУРЧАКНЫ ҺАВА ТОРЫШЫНА КАРАП КИЕНДЕР.
КИЕМ РӘСЕМЕ ЯНЫНА ❄ ЯКИ ☀ БИЛГЕЛӘРЕН ЯСА.




РӘСЕМНӘР АРАСЫНДА 7 АЕРМА ТАП.





ТӨРЛЕ КИСӘКЛӘРДӘН 5 РӘСЕМ ҖЫЙ. АЛАРДА НӘРСӘ ЯСАЛГАН? БУ ӘЙБЕРЛӘРНЕ СИН НИЧЕК КУЛЛАНАСЫҢ?





ТАБЫШМАКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛАРЫН АЛДАГЫ УЕННАН ТАП.

ҮЗЕ ШОМА,
КҮБЕККӘ КҮМӘ.
ХУШ ИСЛЕ,
ЙӘ, КЕМ БЕЛӘ?

ҮЗЕ ТЕШЛЕ,
ЛӘКИН ТЕШЛӘМИ.

Җаваплар salavatkupere.com сайтында.


Республика балалар клиник хастаханәсендә дәваланган нәниләр иҗаты.



Юлия ДУТЛОВА,
Казан, 9 яшь.



Әдилә ЗАКИРОВА,
12 яшь.



Раил МӘҮЛИЕВ,
15 яшь.



Раил ГЫЙМАТОВ,
8 яшь.



Алексей ЕФРЕМОВ,
12 яшь.



Ясминә СИБГАТУЛЛИНА,
6 яшь.



Даниил ГАЛАНИН,
8 яшь.



Әдилә МУСИНА,
9 яшь.



Альбина ГӘРӘЕВА,
Казан, 11 яшь.

СИНЕҢ РӘСЕМНӘРЕҢНЕ ДӘ КӨТЕП КАЛАБЫЗ!



Эмиль ИБРАҺИМОВ, 12 яшь.



Дилә ШӘВӘЛИЕВА, 9 яшь.



Ольга ГРИШИНА, 11 яшь.



Дәринә ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА, Алабуга, 12 яшь.



Динә ХИСМӘТОВА, 7 яшь.



Марсель СӘЛИМОВ, 7 яшь.

СЧАСТЬЕ

Что такое счастье? Я часто задаю себе этот вопрос, но не могу на него ответить. Может потому, что слишком много ответов?

– Счастье – это быть рядом с семьей. Она любит и ценит, поймет и даст совет!

– Счастье – это быть с друзьями. Они всегда утешат.

– Счастье – это мир во всем мире. Ведь жить дружно – счастье!

– Счастье – это когда ты умеешь мечтать, желать и при этом все сбывается.

И все таки ответов много, но главный из них:
«Счастье – это быть здоровым!»

Кристина ОСИПОВА,
Зеленодольск,
10 школа, 5 класс.

СӘЛАМӘТЛЕК

ФИЗКУЛЬТ-СӘЛАМ!

Иртә белән физзарядка ясау зарур. Форточкаларны ачып, матур музыка куеп, гаилә белән бергәләшеп биеп алырга була.

Иренмим беркайчан да,
Иртән торып басам да.
Физзарядка ясый башлыйм,
Тәрәзәмне ачам да.

Менә шундый уен уйнарга да була:

Тезелеп басабыз. Бер-беребезгә тупны баш аркылы тапшырабыз. Иң соңгы кеше тупны кулына алып, яңадан беренче урынга йөгерә. Шул рәвешле уен дәвам итә. Ә хәзер юынырга һәм тешләрне чистартырга йөгерәбез!



ДӨРЕС ТУКЛАНУ – СӘЛАМӘТЛЕК НИГЕЗЕ!

Балалар бакчасына яки мәктәпкә иртәнге ашны ашап киту мөһим. Иртә белән эремчек, төрле боткалар бик файдалы. Кайнар ризык белән туклангач хәрәкәтләнергә генә түгел, уйларга да җиңел булачак.
Икенче мөһим кагыйдә – көнгә 4-5 тапкыр туклану. Алар арасында аерма 4 сәгать булырга тиеш. Кичкә таба җиңелрәк ризыклар ашау мөһим.

КЕМ НИНДИ СПОРТ ТӨРЕ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНӘ?



ДӘРЕСЕ



ДУСЛАРЫМ, МИҢА ИРТӘНГЕ АШКА НӘРСӘ АШАРГА ИКӘН?



Итле ашларны төшке ашта кабул итсәң, кичке ашка сөтле, яшелчәле, балыклы ризыклар куллану дөрес булыр.
Өченче кагыйдә – ризыкны төрләндереп туклану. Көнгә 400 грамм яшелчә һәм җиләк-җимеш ашарга кирәк. Фаст-фуд, чипсы, лимонад, чупа-чупс организмга файдалы түгел, аларда консервантлар күп. Тешләр бозылмасын өчен конфетларны сирәк кенә ашарга тәкъдим ителә.

КУЛЛАРНЫ ЮУ – ШӘХСИ ГИГИЕНАНЫҢ ТӨП КАГЫЙДӘСЕ!

Тырнаклар астына микроблар белән пычрак җыела. Шунлыктан аларны сабынлап, махсус щеткалар файдаланып, ныклап юарга кирәк. Кулларны урамнан өйгә кергәч, бәдрәфтән чыккач, ашарга утырыр алдыннан әйбәтләп җылы су һәм сабын белән юу мөһим.

Кулларыгызны ешрак юыгыз һәм сәламәт булыгыз!

АШАР АЛДЫННАН ШАЛАЙГА КУЛЛАРЫН НӘРСӘ БЕЛӘН ЮАРГА КИРӘК?





Ә сез беләсезме?



Медицина кеше организмын, авыруларны һәм аларны дәвалауны өйрәнә. Аның тарихы бик күптәнгә карый. Борынгы заманнарда авыру кешене дәвалау өчен төрле догалар укыганнар, өшкергәннәр. Соңрак төрле үлән чәйләре һәм башка халык медицинасы алымнары кулланганнар. Шуннан дәвалаучылар кеше организмының үзенчәлекләренә игътибар итә башлый. Бу чорда медицина өлкәсенә Гиппократ, Герофил, Гален дигән галимнәр зур өлеш кертә.



Мәсәлән, борынгы грек дәвалаучысы Гиппократ авыруларны тикшереп, аларның билгеләрен язып бара. Авырган кешеләргә төрле дарулар, үлән сулары эчәргә куша.
Мисырда гигиенага нык игътибар бирәләр, йокы, ашау, юыну вакытлары да төгәл бүленгән була. Мисырлылар җиде йөздән артык үләннең шифасы турында белә.
Борынгы Кытай, Япония, Тибетта энә кадау, массаж кебек дәвалау төрләре барлыкка килә.



Урта гасырларда дәваханәләр, югары уку йортларында медицинаны өйрәтүче бүлекләр барлыкка килә. Төрле китаплар языла, тикшерүләр һәм тәҗрибәләр эшләнелә. Бу вакытларда медицина өлкәсенә гарәп илләреннән Харун әр-Рәшид, Әхмәд ибн Тулун, Әбу Гали ибн Сина, Ибн Зухр дигән табиблар зур өлеш кертә. Медицина өлкәсендә татарлардан беренче профессор, галим һәм күренекле терапевт булып Әбүбәкер Терегулов танылa. Бүген Ренат Акчурин, Айрат Фәррахов, Шамил Гайнуллин, Рәмис Фатыйхов һәм башка атаклы табиблар безгә яхшы таныш.

Медицинаның күптөрле бүлекләре бар. Алар һәрберсе теге яки бу авыру буенча эшли. Шуңа күрә без хирург, балалар, теш, күз табибы һәм башка табибларны беләбез. Медицина үзендә биология, химия, анатомия һәм башка фәннәрне берләштерә. Алар бергә үрелеп, бер-берсен тулылындырып торалар.

Медицина бүгенге көндә дә үсүен дәвам итә. Яңа дәвалау алымнары, дарулар, җиһазлар барлыкка килә, хастаханәләр төзелә. Димәк, медицина кешеләргә төрле авырулардан дәваланырга ярдәм итә. Ләкин табибларга мөрәҗәгать иткәнче, авыруларны булдырмау өчен тырышу дөресрәк. Моның өчен кечкенәдән чисталык кагыйдәләрен үтәргә, дөрес тукланырга, көндәлек режимны сакларга, тешләрне чистартырга, чыныгырга, саф һавада йөрергә, гомумән, сәламәт яшәү рәвеше алып барырга кирәк.

ТАБИБНЫҢ СУМКАСЫНА КИРӘКЛЕ МЕДИЦИНА КОРАЛЛАРЫН САЛ ҺӘМ РӘСЕМНЕ БУЯ.



САУЛЫК ЮЛЫ


ДУСКАЙ! СИНЕҢ АЛДЫҢДА ӨР-ЯҢА УЕН. СӘЛАМӘТЛЕККӘ ФАЙДАЛЫ ШӨГЫЛЬЛӘР БУЕНЧА УКЛАР ЯРДӘМЕНДӘ ЮЛНЫ ҮЗЕҢ ТӨЗЕП КАРА. УЕН БАРЫШЫНДА ҺӘР РӘСЕМГӘ АҢЛАТМА БИРЕРГӘ ОНЫТМА. ӘЙДӘ, СТАРТКА!



СТАРТ!




























12
9
3
6




ЧИСТА СУ




ЧИПСЫ





Роза ТУКТАРОВА

ШАПШАК МАЛАЙ

Әкият

Борын-борын заманда түгел, бүгенге көннәрдә яшәгән, ди, бер Айзат исемле малай. Айзат бик шапшак һәм әдәпсез булган. Муенын да юмаган, тешләрен чистартмаган, чисталыкны һич тә яратмаган. Бер көнне Айзатның киемнәре җыелганнар да гөр килеп бәхәс куптарганнар. Беренче сүзне күлмәк башлаган:

– Айзат минем җиңемне кичә малайлар белән сугышып чак кына өзеп чыгармады. Бер төймәмне өзеп алып конфет урынына суырып йөри. Якамның карарлыгы калмады, каешланып беттем.

– Мине күрегез, зинһар, мине! – дип кычкырып җибәргән чалбар. Тезләрем тишек, кесәләрем ертылган, балакларым балчыкка каткан, нинди хурлык!

Шкаф башыннан сыңар ботинка тавышы ишетелгән:

– Зинһар өчен мине моннан төшерегез. Мине Айзат шкаф башына бәрде, игезәк сыңарым урамда балчыкка батып калды.

Ботинканы бар да кызганган һәм шкаф башыннан төшәргә булышканнар. Шулвакыт кемнеңдер кычкырып елаган тавышы ишетелгән, бу бүрек икән:

– Минем колагым өзек, йоннарым тузгып тора, – дигән ул. Мине Айзат чана урынына кулланып таудан шуды.

– Ах! Нинди әдәпсезлек, – дип уфтанганнар киемнәр.

– Нишлибез? Болай яшәп булмый. Әйдәгез, без Айзатны «Шапшаклар» иленә озатабыз.

Кинәт күктә зәңгәр шар пәйда булган, бу шар зурайган һәм аның эченнән тылсымчы кыз чыккан. Кыз шундый матур, чиста, пөхтә икән. Айзатның киемнәре кыздан ярдәм сораганнар.

– Мин сезгә ярдәм итәрмен, – дигән кыз – минем арттан шушы сүзләрне кабатлагыз: «Сим-сим-сим, шап-шак-шак, ялкау – чак-чак». Кинәт өйдән Айзат килеп чыккан, аның колаклары зурайган һәм чәчләре тырпайган, яшел төскә кергәннәр, бер кулы озын, берсе кыска, бер аягы зур, берсе кечкенә икән. Ә Айзат үзе кычкырып елый ди:

– Кая минем киемнәрем? Нигә мин шундый ямьсез булдым? – дигән ул. Киемнәр бер авыздан җавап биргән:

– Чөнки син шапшак, ялкау. Шуңа без – киемнәрең синнән качтык.

– Минем кире үз хәлемә кайтасым килә. Миңа нишләргә кирәк?

– Хуш исле, шома сабын, ялтырап тора торган теш щеткасы, сөлге белән дус булсаң һәм безне – киемнәреңне юып төзәтмәләр кертсәң, үз хәлеңә кайтырсың, – дигән киемнәр.

Шул көннән башлап Айзатка акыл кергән. Төпле, пөхтә малайга әйләнгән. Ә киемнәре аңа кире әйләнеп кайткан, ди.





ИЗГЕЛЕК ЙОРТЫ



Еш кына балаларыбыз мәктәптә өй эшләре күп бирүгә, компьютер уеннары уйнарга рөхсәт итмәүгә зарланырга ярата. Балалар республика клиника хастаханәсе территориясендә урнашкан «Роналд Макдоналд йорты»на барып кайткач, бу уйлар өчен оялып куясың. Чөнки иң зур бәхет ул – якыннар, туганнар янәшәсендә булу. Моны, авырып киткәч, бигрәк тә яхшы аңлыйсың.

Беренче «Роналд Макдоналд йорты» 1974 елда Америкада Филадельфия шәһәрендә төзелә. Хәзерге вакытта 33 илдә 328 йорт эшли. Әлеге йортта яшәү балаларга тизрәк савыгырга ярдәм итә.

Казандагы «Роналд Макдоналд йорты» – Россиядәге беренче проект. Ул беренче тапкыр ишекләрен 2013 елның 10 июлендә ача. Монда дәваланучы балалар янында әти-әниләре дә яши ала. Шушы елларда «Роналд Макдоналд йорты» йөзләгән балага сәламәтрәк һәм бәхетлерәк булырга ярдәм итте.

Әлеге йорт 24 бүлмәдән тора. Аларның һәрберсендә барлык уңайлыклар, кунак бүлмәсе бар. Шулай ук ашханә, кер юу, уен бүлмәләре эшли. Монда дәваланганда гаилә белән бергәләп ял итәргә, аралашырга да була.

Ә иң мөһиме – бирегә һәрвакыт кунаклар күп килә. Алар белем-тәҗрибәләрен балалар белән уртаклаша, һәркемгә игътибар бүләк итә. «Салават күпере» журналы хезмәткәрләре исә монда туңдырма ясау мастер-классында булды. Фотоларны сезгә дә тәкъдим итәбез.





ТЕЛӘГЕ БУЛГАН ҺӘРКЕМ «РОНАЛД МАКДОНАЛД ЙОРТЫ»НА ЯРДӘМ ИТӘ АЛА. Ә НИЧЕКИКӘНЕН (843) 237-36-23 ТЕЛЕФОНЫ АША БЕЛЕП БУЛА.





БЕРЕНЧЕ ЯЗЫЛУЧЫ-3

ДУСЛАР, 2012 НЧЕ ЕЛНЫ УЗДЫРГАН «БЕРЕНЧЕ ЯЗЫЛУЧЫ» БӘЙГЕЛӘРЕ БИК УҢЫШЛЫ УЗГАН ИДЕ! БҮГЕННӘН КАБАТ ИҢ ӨЛГЕР УКУЧЫБЫЗНЫ ЭЗЛИ БАШЛЫЙБЫЗ.
Бүләгебез дә шәп – заманча телефон.



«БЕРЕНЧЕ ЯЗЫЛУЧЫ» БӘЙГЕСЕНДӘ КАТНАШУ ШАРТЛАРЫ:

1. Почта бүлекләрендә «Салават күпере» журналына (индексыбыз Россиядә – 73953, Татарстанда – П2339) 2017 елның беренче яртыеллыгына 6 айга языл.
2. Катнашучы купонын тутыр һәм кисеп ал. Аның кире ягына почта квитанциясенең күчермәсен беркет.
3. Икесен бергә, конвертка салып, «Беренче язылучы» тамгасы белән редакциягә җибәр (420066, ТР, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 йорт, «Салават күпере» журналы редакциясе).

Хатлар 2016 елның 1 декабренә кадәр кабул ителә. Декабрь аенда жюри, катнашучылар арасында җиңүчеләрне билгеләячәк.
Уңышлар!

КАТНАШУЧЫ КУПОНЫ:

Фамилиям: ____________________

Исемем: ____________________

Яшем: ____________________

Почта адресым: ____________________

Телефоным: ____________________

№10 (319) – 2016

Журнал 1990 елның март аеннан бирле чыга. Журнал выходит с марта 1990 года.

Директор
Зиннур ХӨСНИЯР (Зиннур Зыятдин улы ХӨСНЕТДИНОВ)

Баш мөхәррир
Зилә ЯЗ (Зилә Зиннур кызы ХӨСНЕТДИНОВА)

Баш мөхәррир урынбасары
Гүзәл ЗИННӘТУЛЛИНА

Мөхәррирләр
Гөлназ ЯРМИЕВА
Алсу НИЗАМИЕВА

Баш рәссам
Әлфия ЙОСЫПОВА

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

0+ Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Басарга кул куелды 20.09.16 ел.
Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Гарнитура – PT Sans.
Офсет ысулы белән басыла.
Заказ: М-2451. Тираж: 8650 данә.

Килгән хатлар, кульязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми, авторларга кире кайтарылмый.

Почта гаебе белән журнал өегезгә килеп җитмәсә, түбәндәге телефон белән газета-журналлар экспедициясенә шалтырата аласыз: (843) 562-10-66.


Журналны гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖ.

Татарстан республикасы матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәмендә чыгарыла.

Бәясе ирекле.
ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ:
Татарстанда – П2339
Россиядә – 73953.

Тышлыкта Әлфия Йосыпова рәсеме.

Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ, 420097, Казан, Академическая ур., 2 й.
Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2 й., 10 кат.
Тел.: (843) 519-45-89.
E-mail: salavatkupere@mail.ru
Сайт: www.salavatkupere.com

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт тарафыннан ФС77-54277 номеры белән 2013 елның 24 маенда теркәлде.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 й.



Республика балалар клиник хастаханәсе үзендә хастаханә, югары технологияләр стационары һәм ашыгыч ярдәм күрсәтү функцияләрен берләштерә. Ул Россия Федерациясенең иң зур балалар хастаханәләре бишлегенә керә. Хастаханәгә 1977 елда нигез салына. Бүгенге көндә биредә Татарстанның барлык төбәкләреннән төрле юнәлешләр буенча 17 яшькә кадәрге балалар дәвалана. 2010 елдан хастаханәне Рафаэль Фирнаял улы Шәвәлиев җитәкли.

1



КАБУЛ ИТҮ БҮЛЕГЕ. АШЫГЫЧ ЯРДӘМ ЗОНАСЫ. 1 НЧЕ ТЕРМИНАЛ.

2



КАБУЛ ИТҮ – ДИАГНОСТИКА КОРПУСЫ. 2 НЧЕ ТЕРМИНАЛ.

3



2 НЧЕ ДӘВАЛАУ КОРПУСЫ. 3 НЧЕ ТЕРМИНАЛ.

4



1 НЧЕ ДӘВАЛАУ КОРПУСЫ. 4 НЧЕ ТЕРМИНАЛ.

5



1 НЧЕ ДӘВАЛАУ КОРПУСЫ. КАРДИОЛОГИЯ, ПЕДИАТРИЯ, ПУЛЬМОНОЛОГИЯ.

6




ЯШҮСМЕРЛӘР ҮЗӘГЕ. 6 НЧЫ ТЕРМИНАЛ.

7



1 НЧЕ КОНСУЛЬТАЦИЯ ПОЛИКЛИНИКАСЫ. 7 НЧЕ ТЕРМИНАЛ.

8



РОНАЛД МАКДОНАЛД ЙОРТЫ.

9



АДМИНИСТРАТИВ-ХУҖАЛЫК КОРПУСЫ, КАФЕ.